ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12 декабрь 2022 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3404**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге 1726 номерлы карары белән расланган, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасы рәсмиләштерү, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге 1726 номерлы карары белән расланган, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасы рәсмиләштерү, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2 бүлегенең 2.10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм оешмалар һәм вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүләр исемлеге.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.».

1.2. Административ регламентның 3 бүлегенең 3.1.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Кирәкле мәгълүмат булмаган очракта һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мәгълүматне раслау максатында, 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү.».

1.3 Административ регламентның 3 бүлеген 3.3.4 - 3.3.6. түбәндәге эчтәлекле 3.3.3.6 пунктлар өстәргә:

«3.3.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен нигез булып торган хәлләр барлыкка

килгәндә, муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүләр нәтиҗәләрен әзерләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрергә, шул исәптән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрергә, аларга җаваплар алырга, шуннан соң мөрәҗәгать итүчегә мондый хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәләрен тиз арада алу өчен тиешле хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать бирү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүгә карата, киләчәктә аны күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедә нигез барлыкка килә ала торган, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгате булган очракта, тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрергә, шул исәптән ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрергә, аларга җаваплар алырга, тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен формалаштырырга, шулай ук аны мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга һәм башкарылган чаралар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итәргә;

3) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясындагы 1 өлеше нигезендә алдан язылып ( проактив режимда), ягъни автомат рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе административ регламент белән билгеләнә.

3.3.3.5. Гомуми билгеләр белән берләшкән аерым категория мөрәҗәгать итүчеләргә күрсәтелгән хезмәтне күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата да.

3.3.3.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гомуми билгеләр белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең категориясенә карамый. Шуңа бәйле рәвештә, гомуми билгеләре белән берләшкән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтүнең вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми.».

1.4 Административ регламентка кушымтаны (белешмәне), әлеге карарның кушымтасында бирелгәнчә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2022 елның
12 декабрендәге 3404 номерлы
карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 июлендәге 1726 номерлы карары белән расланган, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасы рәсмиләштерү, даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча маршрут картасын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Хәбибуллин Зөлфәт Флүн улы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары | **8-84371-5-37-99** | Zulfat.Habibullin@tatar.ru |
| Ясельская Регина Романовна - «Төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ җитәкче урынбасары | **8-84371-4-84-77** | Regina.Yaselskaya@tatar.ru |